СОВЕТ НОРМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
НОРМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«19» сентябрь 2025 ел № 6

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге башкарма комитеты житәкчесе вазыйфасын билэүгә конкурс уздыру тәртибе турында һәм конкурс комиссиясе эше тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында**

«Россия Федерациясендә жирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон белән, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районынын Норма авыл жирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Норма авыл жирлеге советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге башкарма комитеты житәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында һәм конкурс комиссиясе эше тәртибе турында нигезләмәне, 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл жирлеге башкарма комитеты житәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2015 елның 11 сентябрендәге 155 номерлы Норма авыл җирлеге Советы карарын үз көчен югалткан дип танырга һәм конкурс комиссиясе эше тәртибе турында»

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендында һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында халыкка житкерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл жирлеге башлыгы Р.Н. Шарипжановка йөкләргә.

Норма авыл җирлеге башлыгы Р.Н. Шарипҗанов